| Республика Татарстан<br>Исполнительный комитет<br>Большенуркеевского сельского<br>поселения Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районының Зур Нөркәй<br>авыл җирлеге башкарма<br>комитеты |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 15 март № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 24 декабрендәге 14 номерлы карары белән расланган җир кишәрлекләрен милеккә алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентның үз көчен югалтуын тану турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 19 декабрендәге 433-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 4 сентябрендәге 1355 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 24 декабрендәге 14 номерлы карары белән расланган җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламент үз көчен югалткан дип санау (23 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе Р.М.Гайсин